# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең Акъяр авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2023 елның 24 октябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елнын 20 октябрендә 8.00 сәгатьтә, 20 октябрендә 9.00 сәгатьтә, 20 октябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең Акъяр авылында узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде: «2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең Акъяр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, тыл хезмәтчәннәреннән; Россия Кораллы Көчләренең хәрби хезмәткәрләре контракт буенча хәрби хезмәт күрсәтүчеләрдән, мобилизацияләнүчеләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, хәрби сугыш ветераннарыннан, 1 төркем инвалидлардан , 85 яшьтән узган гражданнардан тыш , һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Акъяр авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су башняларын, коеларны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итү, аны чистарту, резидентларны су белән тәэмин итү;

-халык яшәгән район чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын тәртипкә китерү, ремонтлау, хезмәт күрсәтү».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 262 кеше кертелгән, 163 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен - гражданнар җыенында катнашкан 159 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең Акъяр авылында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. « 2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең Акъяр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, тыл хезмәтчәннәреннән; Россия Кораллы Көчләренең хәрби хезмәткәрләре контракт буенча хәрби хезмәт күрсәтүчеләрдән, мобилизацияләнүчеләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, хәрби сугыш ветераннарыннан, 1 төркем инвалидлардан , 85 яшьтән узган гражданнардан тыш , һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Акъяр авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын, су башняларын, коеларны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү

чыганакларыннан су алуны тәэмин итү, аны чистарту, резидентларны су белән тәэмин итү;
-халык яшәгән район чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган җәмәгать юлларын тәртипкә китерү, ремонтлау, хезмәт күрсәтү.» карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Акъяр авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/,» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: (httr://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге башлыгы Д.С.Гайнуллин